БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_03_» ___02___ 2020 г. № _81_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 августындагы 289 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октяберендәге 131 номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2014 елның 31 декаберендәге үзгәрешләр белән), «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декаберендәге 273 номерлы федераль закон, «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 бүлегенең 1.2 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

- бер гаиләдә яшәүче һәм уртак яшәү урыны булган балалар абыйлары һәм (яисә) апалары укый торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга (1-4 сыйныфлар) өстенлекле кабул итү хокукына ия.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов